Чыганак: Ак чәчәкләр бүләк итте: Габдрахман Әпсәләмов турында истәлекләр / төз., кереш сүз авт. Г. Мөхәммәдова; рәс. Р. Сәйфуллина. – Казан : Мәгариф, 2001. – 159 б. : рәс. б-н.

Ул чакларда Габдрахманның үзе турында яхшы сүзләр дә, күңелгә ятышсыз сүзләр дә ишеткәне булды. Әмма бу югары намуслы әдипнең үзенең беркайчан да, беркайда да, беркем турында да бер генә начар сүз дә әйткәне булмады дисәм, һич кенә дә ялгышмам. Хәтта, үз әсәрләренә карата кайберәүләр тарафыннан тискәре фикер ишеткәндә дә ул эчтән януларын күрсәтмәскә тырышты. Утны тышка чыгармады. Хәер, бу аңа бик кыйммәткә төште бугай. Ләкин үзенең шушы тыйнаклыгы белән ул «кайберәүләрдән» өстен һәм инсафлырак булып калды.

Мактануга, мактауга ул нәфрәт белән, чирканып карый иде. Исемдә, үзенең 50 яшь тулуга багышланган бәйрәм мәҗлесендә Габдрахман үзе турында мактап, купшыланып сөйләүләрен кискен тыйды. Мәҗлесне күбрәк уен-көлкегә, күңел ачуга юнәлдерде.

* * *

Хәтерем ялгышмаса, 1953 елның җәе иде бугай. Габдрахман Әпсәләмов гаиләсе белән бергә Аккош күленә дачага чыкты. Юк, ял итәргә түгел, бирелеп эшләргә! Бу вакытта аның инде берничә романы дөнья күргән иде. Ә хәзер яңа әсәрләр яза иде ул.

Үзен өстәлгә бәйләп куйган шикелле баш күтәрми эшли. Хәзер әле аның яшь чагы, көчле, дәртле чагы. Алда зур планнар. Нарат урманында саф һава иснәп, кошлар җырын тыңлап йөрергә вакыт юк. Эш, эш! Габдрахман Әпсәләмовның бу бер генә сүз белән әйтелә торган девизы иде. Ул шуның белән яшәде, кайгырды, шатланды. Эш белән ул янды да, көйде дә. Тормышны әдип башкача күз алдына да китерә алмый иде кебек.

Шул җәй көннәренең берсендә без — берничә язучы — аның дачасына бардык. Дөресрәге, киң күңелле Магинә ханым (аны Маһинур дип тә йөртә иделәр) безне кунакка чакырган иде.

Билгеле, кунакта чәй дә, мәй дә була дигәндәй, Магинә ханым бу юлы да безне тәмле ашлар белән сыйлады. Шуны да әйтә узыйм: Габдрахманның мин бер генә тапкыр шәраб эчкәнен дә, тәмәке тарткан да күрмәдем. Ул бу нәмәстәләрнең кайчан да булса тәмен татып караганы булды микән? Мөгаен, юктыр.

Чәй янында без шактый озак гапләшеп утырдык. Сүз һаман шул әдәбият, сәнгать турында барды. Сугыштан соң без мондый

сөйләшүләргә бик сусаган идек. Әмма Габдрахман озак утырмады. Бездән гафу үтенеп, үзенең эш кабинетына кереп китте. Хуҗаның кунаклар белән бер кадәр «кырыс» булуына без бер дә гаҗәпләнмәдек, чөнки белә идек: бу кеше эш белән бер генә нәрсәне дә алыштырмый.

Кич булды. Кайбер иптәшләр өйләренә кайтып киттеләр, ә кайберәүләребез кунарга калды. Алар арасында мин дә бар идем. Мин, гадәттә, йокыдан иртә торырга яратам. Бу юлы да беренче «тургай» булып күренмәкче идем. Юк, соңга калганмын. Миннән дә иртәрәк уянган «тургай» бар икән биредә. Әнә, наратлы юл буенда яшел спорт киеме кигән берәү әрле-бирле йөгерә. Кем дисез? Габдрахман Әпсәләмов! Ул инде иртәнге зарядка ясарга керешкән иде.

Бу чакта әле яшь, егет шикелле. Гәүдәсе төз-туры, җитез хәрәкәтле. Йөзе елмаюлы, күзләре шат.

Ул әле бик озак шулай егетләрчә йөрде. Язуын туктаусыз дәвам итте. Җәмәгать эшләренә дә актив катнаша килде. Бер-бер артлы аның яңа китаплары, яңа мәкаләләре дөньяга чыга торды.

Ә беркөнне, һич тә көтмәгәндә генә, шул тап-таза, тормышка чын күңелдән гашыйк булган кеше кинәт кенә авырып китте. Аңа инфаркт булган иде. Башта бу хәбәргә беркем дә ышанмады. Әмма бу чын иде. Габдрахманны ашыгыч рәвештә больницага озаттылар.

Шактый вакыт узгач кына авыру янына керергә рөхсәт иттеләр. Мин дә ашыгып больницага киттем. Язның нәкъ гөрләгән чагы иде.

Урамда чәчәкләр сатып торучы бер карчыктан зур гына букет ала уздым. Габдрахманга яз бүләге булыр дидем.

Менә палатага да барып кердем. Бу вакытта Габдрахман инде савыгып килә иде. Ул әллә ни ябыкмаган, шулай да сизелә, хәле беткән. Әмма авыруга бирешмәгән.

Чәчәкләрне тумбочка өстенә куйдым. Габдрахман аларга карый-карый нәрсәдер уйланып торды.

— Кара син аны, ак сиреньнәр дә була икән,— диде бераз гаҗәпләнеп...

— Була, күрәсең, үзем дә беренче күрәм. Синең бәхеткә... Ак төс шифалы диләр бит...

Габдрахман елмайды. Тагын уйланды. Аннан соң миңа күзләрен кысыбрак карады да:

— Беләсеңме, Нәби дус,— диде,— син бит миңа бик зур бүләк алып килгәнсең...

— Палатага бераз яз төсе керсен дигән идем...

— Анысы дөрес. Чыннан да, хуш исле чәчәкләр рәхәткә талдыралар. Әмма мин башка бүләк турында әйтәм...

— Нәрсә турында? Нинди бүләк? Төшенеп җитмим...

— Мин менә биредә урынга чалкан ятып, түшәмгә карый-карый күңелдән генә роман язарга керештем...

— Ышанам, син тик кенә ятмассың, беләм мин сине. ...Тик докторлар сизеп алсалар, колагыңны борырлар. Сиңа бит бу хәлендә уйларга да рөхсәт ителми булыр...

Габдрахман бу юлы чын-чынлап көлеп җибәрде. Йөзенә шатлык бәреп чыкты. «Чыннан да, докторлар күренмиме?»— дип, тирә-юньгә каранып алды.

— Йөрәкне бик яхшы күрә алар,— диде.— Әмма уйларны бик нык яшереп була икән. Ул роман бит шул докторларның нәкъ үзләре турында булачак. Синең бу ак чәчәкләрең... Габдрахман кинәт тотлыкты, тынып калды.

— Юк,— диде.— Хәзергә әйтмим әле. Соңыннан белерсең...

Габдрахман савыгып чыкты. Тагын эшкә ябышты. Берникадәр вакыттан соң аның клиникада уйланган яңа романы журналда басыла башлады. Ул яңа әсәрнең исеме «Ак чәчәкләр» дип аталган иде. Бер очрашканда ул миңа шул китабын автограф язып бүләк итте. Үзе көлә-көлә әйтә куйды:

— Рәхмәт, китапка син исем куштың бит...

Исемә төште: әнә нинди «зур бүләк» турында сүз алып барган икән ул теге чакта.

* * *

Инфаркттан соң кешегә азрак эшләргә, күбрәк ял итәргә — гел тыныч булырга кушалар. Без дә Габдрахманны инде шушы режим белән генә яшәр дип уйлаган идек. Кая ул, язучы тагын да ныграк эшкә ябышты! Алай гынамы, иҗади командировкаларга чыгып йөрде. Әдәби атналыкларга катнашты. Һәм берчакны бер төркем язучылар белән ул да Пермь өлкәсендәге Барда районына китеп барды. Анда да әдәби атналык уздырыла иде.